ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2021ел. Иске Тәрбит авылы № 9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары һәм бюджет керемнәре баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.2 пунктының өченче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Расларга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге (1 нче кушымта).

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары Исемлеге (№2 кушымта).

2. Әлеге карар, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://styaberdin-kaybici.tatarstan.ru/ һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнашкан «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.Г.Тимофеев

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның «22»ноябрендәге
9 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге**

| Бюджет классификациясе коды | | Исеме |
|---|---|---|
| **Баш администратор керемнәре** | **Авыл җирлеге бюджеты керемнәре** | |
| **Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы** | | |
| 920 | 1 08 04020 01 1000 110 | Россия Федерациясенең законнар актлары нигезендә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 920 | 108 04020 01 4000 110 | Россия Федерациясенең законнар актлары нигезендә вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 920 | 1 08 07175 01 1000 110 | ________________ авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чараларына автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы |
| 920 | 1 11 02033 10 0000 120 | Авыл җирлекләре бюджетларының вакытлыча ирекле акчаларын урнаштырудан керемнәр |
| 920 | 1 11 03050 10 0000 120 | Авыл җирлекләре бюджетлары хисабына ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар |
| 920 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) бүтән керемнәр |
| 920 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетларының чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 920 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 920 | 1 16 02020 02 0000 140 | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән административ штрафлар муниципаль хокукый актларны бозган өчен |

| | | |
|---|---|---|
| 920 | 1 16 07010 10 0000 140 | Тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) тарафыннан муниципаль контрактта, авыл җирлегенең казна учреждениесе тарафыннан төзелгән муниципаль контрактта каралган йөкләмәләрне үтәү срогы чыккан очракта түләнгән штрафлар, неустойка, пенялар |
| 920 | 1 16 07090 10 0000 140 | Муниципаль орган, (муниципаль казна учреждениесе) авыл җирлеге алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, закон яки килешү нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойка, пенялар |
| 920 | 1 16 10031 10 0000 140 | Авыл жирлеге бюджеты акчаларын алучылар иминият очраклары килеп туган очракта зыянны каплау |
| 920 | 1 16 10061 10 0000 140 | Авыл жирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш)төзүдән читләштерелгән чыгымнарны каплау максатларында түләүләр |
| 920 | 1 16 10081 10 0000 140 | Муниципаль контрактны өзгәндә, башкаручының (подрядчының) аны үтәүдән берьяклы баш тартуы (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш) сәбәпле, муниципаль контрактны өзгәндә зыянны каплау максатларында түләүләр |
| 920 | 1 16 10082 10 0000 140 | Муниципаль контрактны өзгәндә авыл җирлегенең муниципаль юл фонды акчалары хисабына финанслана торган, аны үтәүдән берьяклы баш тарту сәбәпле килеп туган зыянны каплау максатларында башкаручының (подрядчының) түләүләре |
| 920 | 1 16 10123 01 0000 140 | 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш 2021 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә кергән акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр |
| 920 | 116 10100 10 0000 140 | Бюджет акчаларыннан законсыз яки максатсыз файдалану нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр |
| 920 | 1 16 11050 01 0000 140 | Әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны ирекле каплаганда муниципаль берәмлек бюджетына күчерелә торган түләүләр (аеруча саклана торган табигать территорияләрендә әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыяннан тыш) |
| 920 | 1 16 11064 01 0000 140 | Авыр йөкләр һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары тарафыннан җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау максатларында түләнә торган түләүләр |
| 920 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| 920 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл жирлекләре бюджетларының салым булмаган башка керемнәре |
| 920 | 1 17 14030 10 0000 150 | Авыл жирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары |
| 920 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 920 | 2 02 29900 10 0000 150 | Җирле бюджетлардан авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 920 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл жирлекләре бюджетларына башка субсидияләр |
| 920 | 2 02 35118 10 0000 150 | Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә берепчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл жирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 920 | 2 02 30024 10 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бирелә торган вәкаләтләрне үтәү өчен авыл жирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 920 | 2 02 39999 10 0000 150 | Авыл жирлекләре бюджетларына башка субвенцияләр |
| 920 | 2 02 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл жирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 920 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |
| 920 | 2 04 05020 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан авыл жирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга бирелә торган акчалата иганәләрдән керемнәр |
| 920 | 2 08 05000 10 0000 150 | Авыл жирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына) күчерелгән артык түләнгән яки артык түләнгән салым, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтару (зачет) өчен, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар суммасы һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентлар суммасы |
| 920 | 202 15001 10 0000 150 | Бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль районнар бюджетларына дотацияләр |
| 920 | 202 15002 10 0000 150 | Бюджетларның балансльлыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә муниципаль районнар бюджетларына дотацияләр |
| **Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы** | | |
| 926 | 1 11 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнарының оператив идарәсендәге һәм алар төзегән учреждениеләрне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 926 | 1 11 09045 10 0000 120 | Авыл жирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр милкеннән тыш), шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән башка) файдаланудан башка керемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| 926 | 1 11 08050 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендә булган мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр милкеннән тыш), шулай ук муниципаль унитар предприятиеләрнең, шул исәптән казна предприятиеләренең мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алынган акчалар |
| 926 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләр башкарудан) бүтән керемнәр |
| 926 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетларының чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 926 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 926 | 1 14 01050 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендә булган фатирларны сатудан керемнәр |
| 926 | 1 14 02052 10 0000 410 | Күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә авыл җирлекләре белән идарә итү органнары (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан алынган керемнәр |
| 926 | 1 14 02052 10 0000 440 | Күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә авыл җирлекләре белән идарә итү органнары карамагында булган учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр |
| 926 | 1 14 02053 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә керемнәр |
| 926 | 1 14 02053 10 0000 440 | Авыл җирлекләре милкендә булган күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр |
| 926 | 1 14 03050 10 0000 410 | Авыл җирлекләре кеременә кергән варисссыз калган һәм башка мөлкәтне сатудан кергән акчалар (күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә) |
| 926 | 1 14 03050 10 0000 440 | Авыл җирлекләре кеременә кергән варисссыз калган һәм башка мөлкәтне (күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә) |
| 926 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |

| | | |
|---|---|---|
| 926 | 1 17 02020 10 0000 180 | Авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алуга бәйле авыл хуҗалыгы житештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл жирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның «22»ноябрендәге
9 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы** Иске Тәрбит **авыл жирлегенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге**

| Бүлек коды | Төркем, төркемчәләр, статья һәм чыганакларның төрләре коды | Исеме |
|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы** | | |
| 920 | 01 05 02 01 10 0000 510 | Авыл жирлеге бюджеты акчаларының башка калдыкларын арттыру |
| 920 | 01 05 02 01 10 0000 610 | Авыл жирлеге бюджеты акчаларының башка калдыкларын киметү |